

Мордовиянен “Юлдаш” жәмгыяви-сәяси газетасы редакциясенә Н.А.Гундерина дигән укучыбыздан хат килде.
Хатта ул “Юлдаш” белән “Известия Мордовии” битләрендә “Мин бәхетле хатын!” Сания Халикова - гаилә, балалар һәм Ватанга мәхәббәт турында” дигән мәкаләне укыгач туган фикерләрен язган.
Н.А.Гундерина (Казан финанс-икътисад институтын тәмамлагач, Мордовия финанс министрлыгында эшләгән) Ромодан районы Белозерье авылында бәхетле гомер итvче, тырышып туган авылы мәктәбендә 30 ел хезмәт иткән педагогик “Хезмәт ветераны” Сания Исхак кызы Халикова Ватаныбызга лаеклы уллар - батырлар тәрбияләве белән сокланып, горурланып яза. Ул тәрбияләгән лачыннарнын исемнәре туган Рес-публикасында гына тvгел, ә анын чикләреннән еракларда да билгеле.  Сания Исхак кызынын оч улы белән хаклы рәвештә хат авторы горурлана. Алар барысы да намуслы, лаеклы, белемле кешеләр; vз Ватанынын патриотлары булып vскәннәр. Олкәннәре - Зәкәрия улы Фәритнен берничә югары белеме бар, юридик фәннәр кандидаты булып тора, хәзерге вакытта ул Мордовия Главасы эшчәнлеген тәэмин итv буенча идарәсен житәкли. Уртанчы уллары Фаиль - югары белем турында оч диплом ала. Бvген ул Мордовия кадастр бәя vзәге директоры урынбасары.
Сания белән Зәкәрия Халиков-ларнын кече уллары Равиль ботен доньяга vзенен кечкенә Ватанын данлый. Ул чын Ватанны саклаучы, берничә “кайнар” ноктаны узган кеше. Тагы кvпторле бvләкләр-наградалар иясе. Батырлык кvрсәтv белән бәйле дәvләт һәм халык алдындагы зур хезмәтләре очен ана Донецк Халык Республикасы Герое исеме бирелә һәм махсус отличие билгесе - Алтын Йолдыз медале тапшырыла. Равиль Зәкәрия улы Халиков – икътисад фәннәр кандидаты, профессор.
Хормәтле киләчәк буын vстерvче ата-аналар, менә кемнәрдән vрнәк алырга кирәк, дип кинәш итә хат авторы Н.А.Гундерина.